| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>Совет Брюшлинского сельского поселения Менделеевского муниципального района | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Менделеевск муниципаль районы<br>Бөрешле авыл җирлеге Советы |

| | |
|---|---|
| Р Е Ш Е Н И Е<br>30.03.2026 | К А Р А Р<br>№ 22 |

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлеге Советының 2014 елның 19 маендагы 116 нчы номерлы карарын үз көчен югалткан дип тану турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 29 статьясының 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының " Бөрешле авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы белән, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Бөрешле авыл җирлеге Советы

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлеге Советының «Муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче аерым категория затларның һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм бу белешмәләрне бастырып чыгару өчен гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибен раслау хакында» 2014 елның 19 маендагы 116 нчы номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://mendeleevsk.tatarstan.ru “Бөрешле авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

Бөрешле авыл җирлеге Советы рәисе Л.А. Смирнова